**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Нырты авыл җирлеге Башлыгы**
**КАРАРЫ**

**3 ноябрь 2023 ел** **№ 5**

**«Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Яңа Чәбия авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2023 елның 15 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Яңа Чәбия авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Яңа Чәбия авылы, Бакча урамы, 55 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәчете йортыда үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар (курсантлар), I төркем инвалидлары, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегенең Яңа Чәбия авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2024 елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Су белән тәэмин итү системасын карап тору һәм ремонтлау, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, проект-смета документациясен эшләү, смета һәм технадзор өчен түләү
- Җәйге чорда территорияне чабу, куакларны кисү, агачларны кисү, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, смета төзү;
- Чишмәгә юл төзү, смета документациясен эшләү һәм түләү, материаллар сатып алу һәм ташу, килешү һәм технадзор буенча эш өчен түләү, БТИ эшләренә һәм хезмәтләренә түләү;
- Урам яктыртуны карап тоту, смета документларын эшләү һәм түләү, комплектлау материалларын сатып алу, ташу һәм урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Кышкы чорда юлларны кардан чистарту, смета документациясен эшләү һәм түләү, материаллар сатып алу һәм ташу, килешү һәм технадзор буенча эш өчен түләү

«РИЗА» «КАРШЫ»?»

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Нырты авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Нырты авыл җирлеге башлыгы: Т.А.Котдусов

СОВЕТ НЫРТИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НЫРТЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ • ОГРН 1021607754560 ИНН 1623001710